# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында**

**1 статья.** Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

"Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" 1994 елның 9 февралендәге 2079-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, №1-2;

"Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2000 елның 19 маендагы 160 номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 6 (5);

"Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1994 елның 9 февралендәге 2080-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 1-2).

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 сентябре
№ 1080